ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЧАЛМАНАРАТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423752, Чалманарат авылы, Үзәк ур.,
2 йорт

СОВЕТ ЧАЛМАНАРАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423752, село Чалманарат,
ул.Центральная, 2

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

02.03. 2021 ел　　　　　　　　　　　　　　　　№ 2

**Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге Советының 07.09.2017 ел, №20 « Чалманарат авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Норматив-хокукый актларны «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге Советының 07.09.2017 ел, №20 «Чалманарат авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11.2. бүлек, Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 12 нче абзац белән тулыландырырга:

«12) җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Чалманаратс авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чалманарат авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Чалманарат авыл җирлеге
Советы Башлыгы　　　　　　　　　　　　　　　　К.С.Ахметов